СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 269 от 09.11.2018
на № ________ от ____________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль район Советының 09.04.2014 елның 245 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турындагы Нигезләмә”гә үзгәрешләр кертү хакында

“Татарстан Республикасы балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында”гы 13.10.2018 ел 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертелү сәбәпле, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе әгзаларының эштән китүе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы прокуратурасының протестына нигезләнеп һәм “Татарстан Республикасы балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында”гы 20.05.2011 ел 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 7 статьясына туры китереп Татарстан Республикасы Саба муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль район Советының 09.04.2014 елның 245 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турындагы Нигезләмә”гә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.1. пунктындагы «балигъ булмаганнарны җинаять һәм җәмәгатьчелеккә каршы гамәлләр кылуга тарту» сүзләрен «балигъ булмаганнарны җинаять, башка хокук бозуга һәм (яки) җәмәгатьчелеккә каршы гамәлләр кылуга, шулай ук үз-үзенә кул салуга җәлеп итүгә тарту» сүзләренә алыштырырга.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турында” 2012 елның 26 апрелендәге 116нчы номерлы карары белән (2013 елның 23 сентябрендәге 211 номерлы, 2015 елның 30 апрелендәге 304 номерлы, 2015 елның 23 октябрендәге 20 номерлы, 2016 елның 28 апрелендәге 58 номерлы, 2016 елның 16 декаберендәге 86 номерлы, 2017 елның 29 августындагы 164 номерлы, 2017 елның 07 ноябрендәге 179 номерлы, 2018 елның 09 гыйнварындагы 193 номерлы, 2018 елның 21 февраленнән 203 номерлы, 2018 елның 04 маендагы 237 номерлы, 2018 елның 31 августындагы 254 номерлы редакцияләрендә) расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. комиссия составыннан И.И. Әхмәтҗановны чыгарырга;

2.2. комиссия составына Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясенең тикшерү идарәссенең Арча районара тикшерү бүлегенең өлкән тикшерүчесе Кәримов Зөлфәт Илдус улын кертергә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында һәм (http://saby.tatarstan.ru) адресы буенча Саба муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны контрольлек итүне Татарстан Республикасы Саба муниципаль район Башлыгы урынбасары Р.Р.Закирҗановка йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы — Р.Н. Минниханов